**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш,
423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав.,
423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ________________ 27.10.2021 ПР-202 К А Р А Р № _________

Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендәге дини оешмаларның дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында

«Дәүләт яисә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 декабрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендәге дини оешмаларның дини милектәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында нигезләмәне, 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Актаныш муниципаль районы муниципаль милкендәге дини оешмаларның дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия составын, 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 0281778300DAAC80B04F73F8D6671EB6BC
Владелец: Габдулхаев Ильшат Ильфатович
Действителен с 25.02.2021 до 25.05.2022

И.И. Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
___________ № ___
1 нче кушымта

Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендәге дини оешмаларның дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турындагы нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендәге дини оешмаларның (алга таба - комиссия) милкен тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия төзү һәм аларның эшчәнлек тәртибен билгели.

2.Комиссия Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән даими нигездә төзелә.

3. Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне комиссия рәисе башкара. Комиссия эшчәнлеген оештыру ягыннан, Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы алып бара.

4. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

а) федераль башкарма хакимият органнарыннан, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүмат соратып ала;

б) үз утырышларында комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча җирле үзидарә органнары, дин өйрәнү, мәдәният, хокук һәм башка өлкәләрдәге оешмалар һәм белгечләр вәкилләрен тыңлый;

в) комиссия эшендә катнашу өчен федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм белгечләр вәкилләрен дин өйрәнү, мәдәният, хокук һәм башка өлкәләрдә җәлеп итә;

г) Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләрне карау өчен эшче төркемнәр булдыра.

5. Комиссия Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендә булган дини милекне дини оешмаларга тапшыру турындагы гаризаларны караганда барлыкка килгән каршылыкларны җайга салу буенча карарлар кабул итә.

6. Комиссия утырышлары шушы Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә, комиссия карарын таләп итә торган мәсьәләләр барлыкка килгән саен уздырыла.

7. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзасы, утырышта ул булмаганда, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язма рәвештә бирергә хокуклы. Комиссия әгъзасы җитди сәбәп белән (отпуск, авыру, командировка) булмаганда, комиссия әгъзасының хокукларын һәм бурычларын биләгән вазыйфасы буенча комиссия әгъзасы вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат башкара.

Комиссия рәисе карары буенча комиссиянең күчмә утырышлары үткәрелергә мөмкин.

8. Комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул аның рәисе тарафыннан имзалана.

Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Кабул ителгән карар белән килешмәгән комиссия әгъзаларының аерым фикере, комиссия карарына кушымта рәвешендә рәсмиләштерелә.

9. Комиссия үз компетенциясе нигезендә кабул иткән карарлар вәкаләтле органнар тарафыннан Актаныш муниципаль районының муниципаль милкендәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында карарлар кабул итү өчен нигез була.

10. Комиссия карары, шулай ук әлеге карар белән килешмәгән комиссия әгъзаларының аерым фикере 7 көн эчендә Интернет челтәрендә урнаштыру өчен вәкаләтле органга җибәрелә.

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
__________ № ___
2 нче кушымта

Актаныш районы муниципаль милкендәге дини оешмаларның дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия составы

Социаль мәсьәләләр буенча Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе;

Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, комиссия рәисе урынбасары;

Актаныш муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасының әйдәп баручы белгече, комиссия секретаре.

Комиссия әгъзалары:

Актаныш муниципаль районы башлыгы урынбасары;

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы;

Мәдәният һәм социаль агарту бүлеге башлыгы;

Иҗтимагый оешма вәкиле (килешү буенча);

Дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән дини оешманың (үзәкнең) җитәкче органы вәкиле (килешү буенча).

Лист согласования к документу № ПР-202 от 27.10.2021
Инициатор согласования: Салимов Д.З. Начальник юридического отдела
Согласование инициировано: 27.10.2021 14:02

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Салимов Д.З. | | Согласовано 27.10.2021 - 14:02 | - |
| 2 | Габдулхаев И.И. | | Подписано 27.10.2021 - 14:51 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН